**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы №47 «14» апрель 2017 ел

2016 елгы Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл
җирлеге бюджеты үтәлеше турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегендәге бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә

Илбәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында 2016 елгы хисапны керемнәр буенча 3 979,8 мең сум һәм чыгымнар буенча 4 116,2 мең сум күләмендә, чыгымнарның керемнәрдән артуын 136,4 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1) әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге бюджеты керемнәре;

2) әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә бюджетлар чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;

3) әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;

4)Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru урнаштырырга.

.

Рәис Л.Р. Әсәдуллина